РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.03.2021 с. Сарманово № 77

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Салым түләүчеләргә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч булу (булмау) турында мәгълүмат җиткерү эшен оештыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 11 декабрендәге 1127 номерлы карарын гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, 2020 елда Татарстан Республикасы консолидацияләнгән бюджетын көтелгән үтәү нәтиҗәләре һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычларына 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия беркетмәсен үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 16 февралендәге 55 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында:

2.8 пункттан түбәндәге эчтәлекле пунктны төшереп калдырырга:

«7) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http://sarmanovo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

ТР Сарман муниципаль районы
Башкарма комитетының
Җитәкчесе Ф. А. Вәлиев